**СОВЕТ СОКУРОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422622 с.Сокуры,
ул. Школьная, д.1
тел: (факс) 8 84378 4-07-83
E-mail: Sokur.La@tatar.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОКУРЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422622 Сокуры авылы,
Школьная урамы, 1 а нчы йорт,
тел: (факс) 8 84378 4-07-83
E-mail: Sokur.La@tatar.ru

**2023елның «11» декабре** **69 номер**

# КАРАР

**«Җир салымы турында» 2021 елның 27 октябрендәге 38 номерлы Сокуры авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында»**

«Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешенә, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында һәм Россия Федерациясе Салым кодексының беренче өлешендәге 78 пунктының икенче абзацының гамәлдә булуын туктатып тору турында» 2023 елның 31 июлендәге 389-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Сокуры авыл җирлеге Советы карар итте **карар кылды**:

1.«Җир салымы турында» 2021 елның 27 октябрендәге 38 номерлы Сокуры авыл җирлеге Советы карарына, кушымта нигезендә, үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә.

2.Әлеге карарның нигезләмәләренең гамәлдә булуы 2023 елдан башлап салым чорлары өчен җир салымын исәпләүгә бәйле хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3.Әлеге карарны Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

4.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

**Башлык-Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Сокуры авыл җирлеге Советы рәисе** **Р.Н. Газизуллин**

*Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Сокуры авыл җирлеге Советының 2023 елның «11» декабрендәге 69 номерлы карарына кушымта*

**«Җир салымы турында» 2021 елның 27 октябрендәге 38 номерлы Сокуры авыл җирлеге советы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

**2 пунктның 2.1 пунктчасының «в» абзацын** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«в) Бөек Ватан сугышы ветераннарын һәм инвалидларын, шулай ук сугыш хәрәкәтләре ветераннарын һәм инвалидларын;»